…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 9 2017. ИЮНЬ
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## ТИЗРӘК! БИЕГРӘК! КӨЧЛЕРӘК!

## Чирмешән районында үтүче җәйге ГТО фестивале уңаеннан махсус чыгарылыш

**2017 нче елның 9-11 нче июнь көннәре районыбыз тарихына бездә үткән Бөтенроссия Җәйге ГТО фестиваленең республика этабы көннәре булып кереп калачак. Әлеге фестивальдә Азнакай, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Түбән Кама, мамадыш, Мөслим, Саба, Спасс районнарыннан һәм Казан, Яр Чаллы шәһәрләреннән килгән 100 дән артык укучы яшьтәшләрем арасында безнең Чирмешән командасы да бар.**



Чтобы сильным стать и ловким,всем нужна нам тренировка. Всех зову до одного к сдаче нормы ГТО!





Тренировка мизгелләре.

**Фестиваль барышында безгә күп сынаулар үтәсе - үзебезнең физик әзерлегебезне генә түгел, физик мәдәният һәм спорт өлкәсендәге белемнәребезне дә күрсәтәсе бар. “Бердәмлектә – Көч!” диләр. Менә без дә, команда белән үзебезнең район данын яклау өчен әзерләнәбез. Тренировкалар... Һәр өлкәдә алга чыгарга омтылып, бөтен көчебезгә тырышабыз. Ашауны да, йокыны да оныттык бугай инде! Дулкынланабыз, бездән дә битәр, остазларыбыз борчыла.**





## ГТО значогыннан СПОРТ осталыгына

Лашман урта мәктәбенең 10 нчы сыйныф укучысы Вафин Рәсим – җәядән ук ату буенча спорт мастерлыгына кандидат - үткән елгы Бөтенроссия Җәйге ГТО фестиваленең республика этабының Абсолют җиңүчессе булды. Ә бүген ул тагы да жаваплырак бәйгедә – Җәядән ату буенча Россия беренчелегенә әзерләнә.



*Минем сезне әлеге Фестивальдә Чирмешән районы данын яклаучы үзебезнең команда белән таныштырасым килә. Командабыз тренировкалар вакытында тәмам дуслашып бетте. “Один за всех, и все за одного!” - бу нәкъ безнең турында. Бер-беребезнең уңышларына сөенеп, җитешсезлекләренә көенеп, бер-беребезгә көч биреп узган тренировка сәгатьләре инде артта калды. Безне җитди сынау – Фестиваль көтә. Уңыш безнең белән булсын, чөнки командабызда иң – иңнәр генә. Ә хәзер һәрберсе белән якыннан танышып үтик. Таныш булыйк, мин - Зөһрә Сафиуллина. Лашман урта мәктәбе укучысы. 9 яшемнән йөзү белән шөгыльләнәм. Сәламәт яшәү рәвешен хуплыйм. Сәламәт тәндә – сәламәт акыл, диләр бит. Үземне тиешле физик формада тотуда миңа спорт бик булыша. Бу фестивальдә катнашу, командабыз составына эләгүем белән горурланам.*



**МИНГАЗОВ МУСА МИНТАХИР улы. Лашман урта мәктәбе укучысы. “Минем иң яратып шөгыльләнгән спорт төрем – йөзү. Йөзергә өйрәтүче һәм ада зур кызыксыну уятучы остазым – Фаиз Билялов. Без аның җитәкчелегендә бик республикакүләм, районара ярышларда көчебезне сынадык, беркайчан да буш кул белән кайтмадык. Әлеге фестивальдә район командасына уңышлар телим, һәм фестиваль позитив ноталарда гына үтсен дигән өметтә калам.” Муса фестивальдә шәхси инивиатива беллән чыгыш ясый.**





Я - Сафин Инсаф Габдуллович. Участник зимнего и летнего фестиваля ГТО. Я люблю хоккей. Моё хобби-хоккей. Моя первая команда это"Стальные совы". Но сейчас у нас в деревне построили хоккейные корт и я зимой с друзьями играю там. Обычно мы играем против команд из соседних деревень. Я не только люблю в хоккей играть, но и смотреть хоккейные матчи по телевизору. Я болею за "Ак барс" и мечтаю увидеть его матчи вживую.

**Мин - Гайсина Русинә Фәрхать кызы. Лашман урта мәктәбенең 7 нче сыйныф укучысы. Спорт – минем яшәү рәвешем. Мин инде мондый фестивальдә икенче кат катнашам. Мин йөзәргә, йөгерергә яратам. Быелгы фестивальдән шатлыклы мизгелләр генә көтәм. Без бик ныклап әзерләндек. Остазларыбызның йөзенә кызыллык китермисе иде.**



Я - Тимирясова Варвара Андрияновна. Закончила седьмой класс МБОУ "Ульяновская СОШ" Я начала заниматься спортом в пять лет,и начала с таким видом спорта как бег на лыжах,когда закончился лыжный сезон перешла на бег. А ещё мы участвуем на соревнования по футболу и баскетболу. За последние три года я много куда съездила и набрала много знаний для себя. Я хожу на хореографию, и мне это нравиться. .



*Меня зовут Евгений. Мне 15 лет. Живу в селе Саминовка. Учусь в 9 классе. Занимаюсь разными видами спорта: национальная борьба (көрәш), легкая атлетика. Особенно люблю бег на лыжах. Регулярно участвую в районных и межрайонных соревнованиях.*



***Меня зовут Михляев Константин Александрович я родился в 2005 году 10 июля .Я живу в селе Старое Ильмово .Я езжу на соревнования, я уже месяц хожу на тренеровку .***





Ә бу – Игорь Захаров. Иске Элмәле авылы егете. Бик тыйнак. Шулай ук күп ярышларда призлы урыннар иясе

***Я призываю заниматься спортом, чтоб не болеть, ребята, никогда. А для этого нам необходимы – солнце, воздух и вода! Ура! Нормы ГТО будем мы сдавать всегда!***

**Меня зовут Вика. Мне 12 лет. Я живу в селе Старое Ильмово. Учусь в 6 классе. Я люблю заниматься спортом, особенно я люблю заниматься легкой атлетикой. Также я участвую в соревнованиях, и в веселых мероприятиях!**



***Алда безне маҗараларга бай сәгатьләр көтә. Алар күңелләребездә шатлык, җиңү куанычы, горурлык хисләренә төрелеп калсын иде. Фестивалебезнең барышы турында, уңышлар, сөенечләр турында газетабызның киләсендә санында язарбыз. Хәерле сәгатьтә, дуслар!***

**Ксения. Ул бу фестивальдә үз мөмкинлекләрен шәхси инициатива белән сыный**



**“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Сафиуллина З. А.**
**Хәбәрләшү өчен телефон: 9274825605**